**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 31 март № 203

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында» 2015 ел, 14 декабрь, 943 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 22 июль, 502 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турындагы нигезләмәдә:

3.11 нче пунктның өченче һәм дүртенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«икенче урынны яулаган конкурс призерына 80,0 мең сум күләмендә бер премия;

өченче урынны яулаган конкурс призерына 70,0 мең сум күләмендә бер премия.»;

4.6 нче пунктның икенче абзацына «яшәү урыны» сүзләреннән соң «, эшләү урыны» сүзләрен өстәргә;

4.7 нче пунктның дүртенче абзацына «табылган коррупциячел факторларны һәм аларны бетерү ысулларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2011 ел, 21 октябрь, 363 нче боерыгы белән расланган форма буенча» сүзләрен өстәргә;

4.8 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гариза бирүченең әлеге Нигезләмәнең 2.2 нче пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве.»;

4.11 нче пунктта «ун баллы» сүзләрен «биш баллы» сүзләренә алмаштырырга;

4.12 һәм 4.13 нче пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.12. Конкурс комиссиясе балларының кушылма саны кимү тәртибендә баллар суммасын бәяләү нәтиҗәләре буенча утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары санына тапкырланган 15 баллдан артык киткән баллар суммасы җыйган конкурста катнашучылар исемлеген төзи.

Әлеге исемлектә беренче нәтиҗәгә ирешкән конкурста катнашучыга беренче урын, икенче һәм өченче нәтиҗәләргә ия булган конкурста катнашучыларга тиешенчә икенче һәм өченче урын бирелә.

Балларның кушылма саны тигез булган очракта, өстенлек бирелә торган конкурста катнашучы, ачык тавыш бирү юлы белән, утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары тавышының гади күпчелеге белән билгеләнә.

4.13. Конкурс комиссиясе конкурста катнашучылар эшчәнлеген бәяләү нәтиҗәләре буенча утырышта катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары санына тапкырланган 15 баллдан артык киткән баллар суммасы җыйган конкурста катнашучылар булмаганда премияне бирмәү турында карар кабул итә яисә өчтән кимрәк премия билгели, әгәр күрсәтелгән суммада баллар җыйган конкурста катнашучылар өчтән кимрәк булса.»;

әлеге Нигезләмәгә кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

бу карар белән расланган норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсын үткәрү комиссиясе (алга таба – комиссия) составында:

комиссия составыннан М.В.Скирданы, Р.Н.Рәхмәтуллинаны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Артём Илдархан улы Галәветдиновны | Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы урынбасарын (килешү буенча) |
| Рамил Әнвәр улы Шәрифуллинны | «Россия дәүләт суд эшчәнлеге университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесенең Казан филиалы (Казан шәһәре) директорын (килешү буенча); |

Марат Бәһрам улы Сөнгатуллинның вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсы турында нигезләмәгә кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 ел, 31 март, 203 нче карары редакциясендә)

Форма

Норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча экспертларның ел саен үткәрелә торган республика конкурсында катнашуга
заявка

1. Гариза бирүченең Ф.И.Ат.ис. (соңгысы – булганда) (физик затлар өчен) / гариза бирүче исеме (юридик затлар өчен) ________________________________________
______________________________________________________________________

2. Гариза бирүченең яшәү адресы (физик затлар өчен) / гариза бирүче урнашкан адрес (юридик затлар өчен) _____________________________________________
______________________________________________________________________

3. Гариза бирүченең паспорт мәгълүматлары (физик затлар өчен) / гариза бирүченең ОГРН, ИНН (юридик затлар өчен) __________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

4. Эш урыны (физик затлар өчен) _________________________________________
______________________________________________________________________

5. Гариза бирүчене норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча эксперт сыйфатында аккредитацияләү турында таныклык саны ______________________
______________________________________________________________________

6. Гариза бирүченең кредит оешмасындагы счеты реквизитлары _________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

7. Конкурсны үткәрү елы алдыннан килгән ел дәвамында Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының яки аларның вазыйфаи затларының муниципаль норматив хокукый актларына, күрсәтелгән хокукый актлар проектларына үткәрелгән коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре буенча җибәрелгән бәяләмәләрнең гомуми саны турында мәгълүматлар (алга таба – бәяләмәләр) ________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

8. Бәяләмәләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча җибәрелгән мотивлаштырылган җаваплардагы гариза бирүче тарафыннан табылган, нигезле дип танылган коррупциячел факторларның гомуми саны турында мәгълүматлар _______________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

9. Бәяләмәләрдә табылган коррупциячел факторларны бетерү ысуллары турында мәгълүматлар ________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

Әлеге заявкага кушымталар:

1) норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза үткәрү буенча бәйсез эксперт сыйфатында аккредитацияләнү турында таныклык күчермәсе;

2) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (юридик затлар өчен);

3) табылган коррупциячел факторларны һәм аларны бетерү ысулларын күрсәтеп, Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2011 ел, 21 октябрь, 363 нче боерыгы белән расланган форма буенча бәяләмәләр күчермәләре;

4) бәяләмәләрне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасындагы дәүләт органнарының, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарының һәм аларның вазыйфаи затларының мотивлаштырылган җаваплары күчермәләре.

Әлеге заявкада, шулай ук аңа теркәлгән кушымталарда тапшырылган бөтен мәгълүмат дөрес булуы турында белдерәм.

_______________________/_________________________________/

(имза) (Ф.И.Ат.ис.) (соңгысы – булганда)

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә каршы килмим.

_______________________/_________________________________/

(имза) (Ф.И.Ат.ис.) (соңгысы – булганда)

М.У. (мөһер булганда)

Дата: ________________

_______________________________